| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 март г.Казань № 185

Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә вәкаләтле органны билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законны, «Урамннан тыш транспорт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законны, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 ел, 20 декабрь, ТРЗ-103 нче Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгын Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар,

30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче; 2018 ел, 12 июль, 565 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 8 август, 643 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

03.03.02 кодлы функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципальара һәм шәһәр яны элемтәсендә һава, су, урамнан тыш, автомобиль транспорты белән (җиңел таксины кертеп (рөхсәтнамә бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнамәнең дубликатын бирү, рөхсәтнамә гамәлен вакытыннан алда туктату, Бирелгән рөхсәтнамәләр реестрын алып бару өлешендә) һәм шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру, җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру»;

Кодификаторның «Өченче» графасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | «03.03.06 | Юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру». | | |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче; 2018 ел, 22 март, 161 нче; 2018 ел, 5 июнь, 430 нчы; 2018 ел, 17 декабрь, 1155 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципальара һәм шәһәр яны элемтәсендә һава, су, урамнан тыш, автомобиль транспорты белән (җиңел таксины кертеп (рөхсәтнамә бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнамәнең дубликатын бирү, рөхсәтнамә гамәлен

вакытыннан алда туктату, Бирелгән рөхсәтнамәләр реестрын алып бару өлешендә) һәм шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру, җиңел такси белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру (03.03.02*)»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру (03.03.06*).»

3.2 пунктта:

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы белән физкультура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);»;

егерме өченче абзацны төшереп калдырырга;

егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07*);»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урамнан тыш транспорт белән йөрткәндә, муниципальара маршрутлар буенча транспорт хезмәте күрсәтү графикларын (расписаниеләрен) раслый;

төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру һәм мониторинглау эшләрен үткәрүне тәэмин итә;

төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыруны, алыштыруны, демонтажлауны һәм карап тотуны оештыра;

гомуми файдаланудагы автомобильләрне куеп тору урыннары реестрын алып бару тәртибен билгели;

төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан гомуми файдаланудагы автомобильләрне куеп тору урыннары реестрын алып баруны оештыра;

төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары яки аларның участоклары өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектларын федераль законнар нигезендә раслый;

юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин